Tatar16.ru

# Нәкый Исәнбәт

(1899 – 1992)

*« Сатмас егет илен алтын көмешләргә,*

*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*

*Алтынны ул чүпкә санар,*

*Иң кыйммәтле күрер Ватанын »*



Tatar16.ru

- *Нәкый Исәнбәт, чын исеме Нәкый Сираҗетдин улы Закиров ( 29 декабрь (10 гыйнвар) 1899 — 1992 елның 12 сентябре) — күренекле татар язучысы, шагыйрь, драматург, галим-филолог һәм фольклорчы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты һәм Татарстанның Халык язучысы. Ул 1899 елның 29 декабрендә (яңа стиль белән 1900 елның 10 гыйнвары) Уфа*
- *губернасы Златоуст өязе (хәзерге Башкортстанның Салават районы) Малаяз авылында Сираҗетдин мулла һәм Таибә абыстай гаиләсендә туган. Аның туган авылы мәңге яшел чыршылар, наратлар белән бизәлгән Урал итәгенә урнашкан. Шунда ул башлангыч белемне ала.*

Tatar16.ru



- 1910 елданУфада «Хөсәения» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә укый. Балачакта дикъкать белән кат-кат укылган әсәрләр аның зиһенендә яңа матур уйлар тудыра. Озакламый Нәкый үзе дә шигырьләр яза башлый. «Шүрәле» исемле беренче шигырен язганда, аңа ун гына яшь була. Озакламый аның шактый калын шигырь

- *дәфтәре шәкертләр арасында тарала. Тәүге шигырьләренә Шәехзадә Бабич фатиха бирә.* 1914-1916 *елларда, Казанда«Мөхәм мәдия» мәдрәсәсендә укыганда, «Аң», «Сөембикә», балалар өчен чыгарылган «Ак юл» һәм «Балалар дөньясы» журналларында поэма һәм драма әсәрләре басылып чыга. Беренче әсәрләренә «Н.И.», «Кара сакал», «Мәргән», «Аллаяр», «Дәрвиш», «Кабил», «Мәлгун» һ.б. псевдонимнары*

Tatar16.ru



Tatar16.ru

- *Нәкый Исәнбәт туган якларындагы Атау, Тастүбә, Үрге Кыйгы мәктәпләрендә татар телен укыта (1917 елның көзеннән,* 1920 *елның җәенә кадәр), халык авыз иҗатын җыю белән мавыга. Унике яшеннән башлап, ул дәфтәренә мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыя башлый. Гомере буе туплаган халык авыз иҗаты әсәрләрен аерым җыентыклар рәвешендә бастырып чыгара*
- *(«Татар халык мәкальләре» (өч томда), «Табышмаклар», «Балалар фольклоры»).*
- 1920-1922 *елларда, укытучылык эшеннән аерылмыйча, Уфа халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетының халык мәгарифе факультетында укый.*

- 1941 елның июнендә Мәскәүдә узасы Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек барган вакытта Исәнбәтне искә төшерәләр. Декада программасына Татар дәүләт академия театры «Хуҗа Насретдин» һәм «Идегәй» спектакльләре премьерасын әзерли. «Идегәй» трагедиясе Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының 1944 елда Татарстанда идеология эшенең торышына, әдәбиятка

Tatar16.ru

- һәм ул куярга да, бастырып чыгаруга да яраксыз табыла.



Tatar16.ru

- *Туган әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендәге игелекле хезмәтләре өчен Нәкый Исәнбәткә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Татарстанның Халык язучысы дигән исем бирелде.*
- *Татар халкының рухи тормышында, сәнгать һәм әдәбиятында Нәкый Исәнбәт иҗаты күренекле урын алып тора.*
- *Нәкый Исәнбәт 1992 елның* 12 *сентябрендә Казанда вафат була.*